**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423750, Уразай авылы, Үзәк ур., 4 йорт

**СОВЕТ УРАЗАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423750, дер.Уразаево, ул.Центральная, 4

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**№ 4** **15.04.2019ел**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февралендәге 2/2 номерлы «Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре һәм аларның вазыйфаи хәлләренә яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны тормышка ашырудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Советы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлеге

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февралендәге 2/2 номерлы «Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре һәм аларның вазыйфаи хәлләренә яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны тормышка ашырудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында":

1.1. 2 өлешнең 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен «комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән " сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Уразай авыл җирлеге»бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге Совет Рәисе Р.Р.Шарипов